ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки муниципаль районы
Иске Камка авыл җирлеге
Советы

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**Совет Старокамкинского сельского поселения Алькеевского муниципального района**

Адресы: 422897, ТР, Әлки районы, Иске Камка авылы, Түбән урамы,1 йорт
тел./факс 8(84346) 73-524

Адрес: 422897, РТ, Алькеевский район, с. Старое Камкино, ул.Нижняя. д.1
тел./факс 8(84346) 73-524

**РЕШЕНИЕ** **Иске Камка авылы** **КАРАР**

«30» апрель 2025 ел № 111

Әлки муниципаль районы
Иске Камка авыл җирлеге
Советының 2022 елның «15» декабрендәге
55 номерлы «Әлки муниципаль районы
Иске Камка авыл җирлеге
депутатларының, даими нигездә үз вәкаләтләрен
гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнарының
сайлап куела торган вазифаи затларының,
муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә
түләү тәртибе һәм шартлары турындагы
Нигезләмәне раслау турында»гы карарына
үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының « Татарстан Республикасында үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазифаи затларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең, рәис урынбасарларының, аудиторларының, муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәтенә түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 28.03.2018 ел, № 182 карары нигезендә (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 24.04.2018 № 281, 14.06.2018 № 481, 17.10.2018 № 940, 29.12.2018 № 1320, 17.11.2021 № 1087, 13.12.2021 № 1222, 17.09.2022 № 1015, 30.04.2024 № 290, 24.06.2024 № 451, 25.09.2024 № 829, 14.04.2025 № 228 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге Советының 2022 елның «15» декабрендәге 59 номерлы «Әлки муниципаль районы Иске Камка авыл җирлеге депутатларының, даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнарының сайлап куела торган вазифаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы Нигезләмәне раслау турында»гы 16.05.2024 № 86, 13.11.2024 № 95 редакциясендә) карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 нче пунктка түбәндәге абзацны өстәргә:

2025 елның 1 маеннан Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Камка авыл җирлегендә муниципаль хезмәткәрләрнең вазифаи окладлары авыл җирлегендә муниципаль хезмәтнең кече вазифалар төркеме белгеченең вазифаи окладкы күләменә карап исәпләнә, ул 15 389 сумны тәшкил итәчәк.

1 нче кушымтада 2 нче бүлекнең 2.5 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Авыл җирлекләре башлыкларының һәм аларның урынбасарларының хезмәтенә түләү, аларга айлык акчалата бүләкләү шартларын җайга сала торган муниципаль хокукый акт белән билгеләнгәндә, күрсәтелгән затларның хезмәтенә түләү чыгымнары күләме айлык акчалата бүләкләүне түләү өлешендә башлыклар өчен – елына 15,48 айлык акчалата бүләкләү, аларның урынбасарлары өчен елына 17,27 айлык акчалата бүләкләү нормативларыннан артмаска тиеш».

1 нче кушымтада 3 бүлекнең 3.2 пунктындагы 5 пунктчасының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) җирле үзидарә органнары структурасы стандартларын кертүгә бәйле рәвештә җирле үзидарә органнары структурасын үзгәртеп корганда, муниципаль хезмәткәрне элек биләгән вазифаи окладына караганда кечерәк булган муниципаль хезмәт вазифасына билгеләү очрагыннан тыш, муниципаль хезмәткәрне акчалата бүләкләү күләме вазифаи окладның 58 процентыннан артмаган күләмдә ай саен элеккеге вазифасы буенча акчалата бүләкләү күләменә кадәр исәпләнә».

1 нче кушымтада 4 бүлекнең 4.1 пунктындагы 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6) айлык акчалата бүләкләү – вазифаи окладларның 58 процентыннан артмаган күләмдә;"

2. 4 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

3. Әлеге Карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырырга: http://pravo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә.

Әлки муниципаль районы
Иске Камка авыл җирлеге Советы башлыгы
урынбасары Р.З.Аглетдинов

Хезмәткәрләр вәкиле белән килешенде
А.Г.Сафина

Әлки муниципаль районы
Иске Камка авыл җирлеге Советының
«Әлки муниципаль районы
Иске Камка авыл җирлеге
депутатларының, даими нигездә үз вәкаләтләрен
гамәлгә ашыручы җирле үзидарә органнарының
сайлап куела торган вазифаи затларының,
муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә
түләү тәртибе һәм шартлары турындагы
Нигезләмәне раслау турында»гы
2025 ел «30» апрель № 111
карарына 4 нче кушымта

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ӘЛКИ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ ИСКЕ КАМКА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫН, ДЕПУТАТЛАРЫН, ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘНЕҢ ҮЗ ВӘКАЛӘТЛӘРЕН ДАИМИ НИГЕЗДӘ ГАМӘЛГӘ АШЫРУЧЫ САЙЛАНУЛЫ ВАЗИФАИ ЗАТЛАРЫН АЙЛЫК АКЧАЛАТА БҮЛӘКЛӘҮ КҮЛӘМНӘРЕ**
**(2025 елның 1 маеннан)**

| Вазифа исеме | Айлык акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | авыл җирлекләрендә |
| | 12 төркем |
| Муниципаль берәмлек башлыгы | 21 091 |
| Муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары | 15 391 |
| Депутат | 15 389 |
| Җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы | 15 389 |